РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 30 октябре Кукмара ш. № 13

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Кукмара муниципаль район Советының 2018 елның 27 апрелендә кабул ителгән 152 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы Карары нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Кукмара муниципаль район Советының 2018 елның 27 апрелендә кабул ителгән 152 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) үзгәрешләр кертергә:

а) Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 1 пунктының беренче абзацында «11 163» санын «11 498» санына алмаштырырга»;

б) Нигезләмәнең 2 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә 2 нче кушымта

МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ, МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ УРЫНБАСАРЫ, КОНТРОЛЬ-ХИСАП ОРГАНЫ РӘИСЕНЕҢ АКЧАЛАТА ТҮЛӘҮЛӘРЕ КҮЛӘМЕ

| Вазыйфа атамасы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 30442 |
| Башлык урынбасары | 27398 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 27398 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев